| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2020 елның 3 июне № 45/6

Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә вазыйфаи затларның аерым категорияләрен катнашу тәртибен камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 7 маендагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы җитәкче вазыйфасына керә торган зат һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2013 елның 13 мартындагы 29/2 номерлы карары (2018 елның 11 маендагы 27/6 номерлы редакциясендә) белән расланган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмәгә, дүртенче абзацта «ел саен, елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча,» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокларда» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров